Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге
составына керүче Әхмәт авылы
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

2020 елның 19 ноябре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Мюд авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 5 ноябрендәге 99 номерлы карары нигезендә, 2020 елның 19 ноябрендә Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегендә Әхмәт авылында узган түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: «2021 елда Мюд авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торычыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгез һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Әхмәт торак пунктында юлларга вак таш салу (вак таш сатып алу)
- Әхмәт торак пункты чикләрендә кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ» «ТЫЕЛДЫЛАР».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 51 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 31 граждан кертелгән.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 31 граждан тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.;

«ТЫЕЛДЫЛАР» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

**Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Әхмәт авылында халык җыенын узган, халык җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.
2.Сорау буенча карар кабул итәргә: «2021 елда Мюд авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торычыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүегез һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Әхмәт торак пунктында юлларга вак таш салу (вак таш сатып алу)
- Әхмәт торак пункты чикләрендә кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)»

3. Әлеге карарны Мюд авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка җиткерергә һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
ТР Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге башлыгы Т. В. Зюзина

СОВЕТ МЮДОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ